КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 11 февраль г.Казань № 142

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы коллегиясе составын раслау турында» 2009 ел, 13 май, 310 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы коллегиясе составын раслау турында» 2009 ел, 13 май, 310 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 ел, 9 октябрь, 701 нче; 2011 ел, 28 апрель, 349 нчы; 2012 ел, 8 ноябрь, 974 нче; 2014 ел, 6 декабрь, 953 нче; 2015 ел, 23 апрель, 276 нчы; 2015 ел, 21 октябрь, 787 нче; 2018 ел, 17 гыйнвар, 12 нче; 2018 ел, 28 август, 724 нче; 2019 ел, 29 октябрь, 968 нче; 2020 ел, 20 август, 713 нче, 2021 ел, 01 декабрь, 1156 нчы, 2022 ел, 7 февраль, 95 нче, 2022 ел, 22 август, 877 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы коллегиясенең санын һәм составын раслау турында»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Түбәндәгеләрне расларга:

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы коллегиясе санын 16 кеше күләмендә;

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы коллегиясенең теркәлгән составын.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы коллегиясе составында:

коллегия составыннан  М.А.Рогожкинны чыгарырга;

коллегия составына Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры урынбасары Кыямов Алмаз Әхтәм улын кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин